**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның «12» сентябреннән № 251

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары баш хисапчыларының һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) вазыйфаи окладларын арттыру турында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләренең һәм белгечләренең, муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, үзәкләштерелгән бухгалтерларның һәм бухгалтерларның хезмәт хакын тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 878 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2022 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары баш хисапчылары һәм хисапчыларының Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары баш хисапчылары һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» 2019

елның 23 апрелендәге 112 номерлы карары белән билгеләнгән вазыйфаи окладлары күләмнәрен 1,04 тапкырга арттырырга.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http//pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов